Раслыйм

«Сәләт» Яшьләр үзәге ДБУ

Директоры

_______________ А.Т. Габдрахманова

«____»_______________ 2021 ел

**«Яшь йөрәкләр» театр лабораториясе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Оештыручылар

«Яшь йөрәкләр» театр лабораториясе (алга таба – Лаборатория) Татарстан Республикасының «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды тарафыннан Яшьләр минстрлыгы каршындагы ДБУ «Сәләт» яшьләр үзәге белән берлектә тормышка ашырыла.

## 2. Лабораториянең максатлары һәм бурычлары

Лабораториянең максаты - киләчәк буынга рухи һәм әхлакый-эстетик тәрбия бирү, яшьләрнең иҗади сәләтләрен ачыклау һәм үстерү, аларны хуплау.

Лаборатория үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

- яшьләрнең иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;
- балаларда һәм яшьләрдә татар театр мәдәниятенә кызыксыну уяту;
- яшь буынны татар театр мәдәнияте кыйммәтләренә җәлеп итү;
- укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыруның яңа ысулларын эзләү, аларның үз халкының мәдәни мирасына кызыксынуы, театр сәнгате ярдәмендә рухи-әхлакый кыйммәтләрне кабул итүенә этәргеч бирү;
- яшьләрнең иҗади үсеше өчен шартлар тудыру;

- ижади тәҗрибә алмашу аша актерлык осталыгы дәрәҗәсен күтәрү;
- яшүсмерләрнең һөнәри ориентациясен билгеләүгә ярдәм итү.
- сәләтле яшьләр арасында яңа исемнәр ачу һәм аларның үсешенә ярдәм итү.

## 3. Лаборатория эшчәнлеге

3.1. Ижади сезонның беренче яртысында (ноябрьдән декабрьгә кадәр) театр уку йортлары актерлары, режиссерлары һәм укытучылары белән ижади очрашулар һәм мастер класслар уза.

3.2. Дәресләр системалы рәвештә алдан килешенгән график белән үткәрелә.

3.3. Ижади сезон дәвамында (ноябрьдән июньгә кадәр) коллектив төрле театр фестивальләрендә катнаша.

3.4. Ижади сезон тәмамлангач, коллектив хисап спектаклен тәкъдим итә һәм курсларны тәмамлау турында таныклык ала.

## 4. Лабораториянең Катнашучылары

Лабораториядә махсус театраль белеме булган яки үзешчән (профессиональ булмаган), гариза биреп теләген белдергән мәктәп укучылары һәм югары уку йортлары студентлары, шулай ук башка учреждениеләрдә белем алган, яки хезмәт иткән яшьләр катнаша ала.

## 5. Лабораториянең сәнгать берләшмәсе

Сәнгать берләшмәсе составына театраль белем бирү учреждениеләре педагоглары, актерлар, режиссерлар, күренекле сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләре керә.

*Координатор проекта: Гульназ Гатина 89003268636*

## 6. Лабораториядә катнашу өчен гаризалар җыю тәртибе

Лабораториядә катнашырга теләүчеләр 2021 елның 20 октябренә кадәр selet.biz сайтында күрсәтелгән формада гариза җибәрергә тиеш.

## 7. Оештыручыларның адреслары һәм контактлары

Лабораториянең оештыру комитеты «Сәләт» йортында (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт, 3-нче кабинет) урнашкан. Барлык сораулар белән проект җитәкчесе Гатина Гөлназ Шәүкәт кызына (+7-843-292-23-30) мөрәҗәгать итә аласыз.

*Координатор проекта: Гульназ Гатина 89003268636*